ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 февраль 2025 ел

№ 1276

Муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтнә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча;

3) муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 3 нче кушымтада каралганча;

4) муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 4 нче кушымтада каралганча;

5) муниципаль мәдәният учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең

хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне, 5 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 19 февралендәге
1276 номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә муниципаль китапханәләр, музейлар, башка музей тибындагы учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре (алга таба – мәдәният хезмәткәрләре) вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге нигезләмәдә төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәтенә түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары;

2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

3) компенсация характерындагы түләүләр.

4. Ел саен бирелә торган яки башка ялда булганда, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда мәдәният хезмәткәренең профиль буенча хезмәт стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, хезмәткә түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлардан соң гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчеләре:

1) белем һәм хезмәт стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында» 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы приказы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килүен тикшерәләр;

2) ел саен барлык мәдәният хезмәткәрләре өчен тариф исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

3) барлык мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакын вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

2 бүлек. Мәдәният хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

6. Мәдәният хезмәткәрләренең база окладлы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет контролеры | 24 966 |
| Музей караучысы | 24 966 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 27 658 |
| Кинотеатрларга, ресторannнарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 27 658 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 27 658 |
| Дискотека алып баручы | 27 658 |
| Билет кассалары мөдире | 27 658 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 27 658 |
| Аттракцион контролер-утыртучысы | 27 658 |
| Мәдәни чаралар оештыручы | 27 658 |
| Фильм фондын ремонтлау һәм реставрацияләү участогы мастеры | 27 658 |
| Экскурсияләр оештыручы | 27 658 |
| Режиссер ярдәмчесе | 27 658 |
| Бию кичәсе җитәкчесе | 27 658 |
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 27 658 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Администратор | 27 958 |
| Администратор (өлкән администратор) | 27 958 |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 27 958 |
| Оркестр артисты | 27 958 |

| | |
|---|---|
| Артист-вокалчы (солист) | 27 958 |
| Библиограф | 27 958 |
| Китапханәче | 27 958 |
| Әйдәүче библиограф | 27 958 |
| Әйдәүче китапханәче | 27 958 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм оешмаларның әйдәүче методисты | 27 958 |
| Баш библиограф | 27 958 |
| Баш китапханәче | 27 958 |
| Аттракцион мөдире | 27 958 |
| Тавыш операторы | 27 958 |
| Кинооператор | 27 958 |
| Лектор (экскурсовод) | 27 958 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм оешмалар методисты | 27 958 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте үзәге (мәдәният һәм ял) һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 27 958 |
| Кинопрограммалар төзү буенча методист | 27 958 |
| Редактор (музыка редакторы) | 27 958 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм оешмалар редакторы | 27 958 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар редакторы | 27 958 |
| Репертуар буенча редактор | 27 958 |
| Иҗади жанрлар буенча белгеч | 27 958 |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | 27 958 |
| Исәп-саклау документлары буенча белгеч | 27 958 |
| Фольклор буенча белгеч | 27 958 |
| Экспозиция һәм күргәзмә бүлеге белгече | 27 958 |

| | |
|---|---|
| Фондларны саклаучы | 27 958 |
| Яктылык буенча рәссам | 27 958 |
| Рәссам-декоратор | 27 958 |
| Рәссам-конструктор | 27 958 |
| Рәссам-бизәүче | 27 958 |
| Рәссам-сәхнәгә куючы | 27 958 |
| Рәссам-реставратор | 27 958 |
| Рәссам-скульптор | 27 958 |
| Рәссам-фотограф | 27 958 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Балетмейстер-сәхнәгә куючы | 28 258 |
| Фондларның төп сакчысы | 28 258 |
| Баш рәссам | 28 258 |
| Зоопаркның ветеринария лабораториясе мөдире | 28 258 |
| Кино- һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | 28 258 |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | 28 258 |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждение һәм оешмаларның бүлек (сектор) мөдире | 28 258 |
| Зоопарк бүлеге (секторы) мөдире | 28 258 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 28 258 |
| Аттракцион техникасын эксплуатацияләү бүлеге мөдире | 28 258 |
| Музейның күчмә күргәзмәсе мөдире | 28 258 |
| Реставрация остаханәсе мөдире | 28 258 |
| Сәнгать-бизәү остаханәсе мөдире | 28 258 |
| Тавыш режиссеры | 28 258 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 28 258 |

| | |
|---|---|
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 28 258 |
| Режиссер-сәхнәгә куючы | 28 258 |
| Клуб берләшмәсе, һәвәскәрләр берләшмәсе, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксыну буенча клуб җитәкчесе | 28 258 |
| Сәнгать җитәкчесе | 28 258 |

7. «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һәм «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| Музей предметларын саклаучы | 27 958 |
| Музей предметларын исәпкә алу буенча белгеч | 27 958 |
| Экскурсовод | 27 958 |
| Тәрҗемәче гид | 27 958 |
| Төп саклаучы | 28 258 |
| Музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире | 28 258 |

«Музей бүлеге (секторы) мөдире», «музейның исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире», «китапханә бүлеге (секторы) мөдире», «мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире», «зоопарк бүлеге (секторы) мөдире», «кино - һәм видеофильмнарны прокатка бирү бүлекчәсе (пункты) мөдире» һәм «сәнгать җитәкчесе» вазыйфалары буенча өстәмә рәвештә база окладына арттыру коэффициенты – 1,1 кулланыла.

## 3 бүлек. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

8. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

монда:
$O_б$ - мәдәният хезмәткәрләренең база оклады;
S - мәдәният хезмәткәре биләгән ставкаларның фактик саны.

## 4 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

9. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы эш нәтиҗәсенә ирешүгә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;

2) квалификация категориясе өчен түләүләр;

3) профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр;

4) башкарыла торган эшнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

5) премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре;

10. Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_{d} \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_{г}$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме сигез процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәренең исемлеге әлеге нигезләмәгә кушымтада бирелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләрнең күләме мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәрнең сайлавы буенча, мактаулы исемнең берсе буенча билгеләнә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_{d} \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда:

$O_{d}$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмәнең күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләме 1 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) приказының датасы нигезендә башкарыла.

1 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмәләрнең күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|

| Әйдәүче звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| 2 квалификация категориясе | 2 |
| 1 квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе, шулай ук «баш» яки «әйдәүче» ясалма исемнәре булган вазыйфалар | 6 |

12. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, һөнәри квалификация төркемнәренә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча хезмәт стажы өстәмәнең күләме.

Профиль буенча хезмәт стажы өстәмәләрнең күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |

| | | |
|---|---|---|
| җитәкчеләр составы вазыйфалары | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

Эш вакыты вазыйфа буенча хезмәт стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан раслана.

Хезмәт стажы үзгәргәндә, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

13. Мәдәният хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып учреждениенең локаль актлары белән раслана торган мәдәният хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Мәдәният учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Мәдәният хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет зурлыклары һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең чик күләмнәре 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең чик күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 14 |
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 22 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 32 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 42 |

14. Хезмәткәрләргә юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә һәм билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнә.

15. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча мәдәният хезмәткәрләренә акчалар булганда бер тапкыр кызыксындыру түләве башкарыла. Бу максатлар өчен түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

16. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локальнорматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

## 5 бүлек. Учреждение җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының һәм баш бухгалтерының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

17. Учреждениеләр җитәкчеләренең, җитәкчеләр урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы вазыйфаи окладтан һәм стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрдән тора.

18. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең оклады хезмәткә түләү буенча төркемгә бәйле рәвештә билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесе хезмәтенә түләү төркеме мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына бәйле рәвештә билгеләнә.

19. Учреждениеләрнең җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының окладлары әлеге учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк итеп билгеләнә.

20. Җитәкчеләрнең хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары

| Учреждение төре | Аена база окладының күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Хезмәткә түләү төркеме | | | | | | | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | хезмәткәрләрнең штат саны (ставкалар) | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500.999 га кадәр | 501 дән артык |
| Китапханәләр | - | 38,0 | 45,0 | 48,5 | 52,0 | 60,0 | 65,0 | - |
| Клублар | 36,0 | 42,5 | 45,0 | 48,5 | 50,0 | 55,0 | 65,0 | - |
| Музейлар | 37,5 | 41,5 | 43,0 | 50,0 | 52,0 | 60,0 | 65,0 | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәдәни - ял үзәге | - | 47,0 | 48,0 | 50,0 | - | - | - | - |

21. Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм аларның авырлык коэффициентлары Башкарма комитет карары белән раслана.

Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне башкарган өчен түләнергә мөмкин.

Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләме 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме

| Учреждение төре | Аена башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткә түләү төркеме | | | | | | | |
| | хезмәткәрләрнең, ставкаларның штат саны | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 елга кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500.999 га кадәр | 501 дән артык |
| Китапханәләр | - | 4,0 | 5,0 | 5,5 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | - |
| Клублар | 3,5 | 4,5 | 5,0 | 5,5 | 6,0 | 6,5 | 7,0 | - |
| Музейлар | 3,5 | 4,0 | 4,5 | 6,0 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | - |
| Мәдәни - ял үзәге | - | 5,0 | 5,5 | 6,0 | - | - | - | - |

22. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесе җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәдәният учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин. Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең чик дәрәҗәсе мәдәният учреждениесе

җитәкчесенең башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

23. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ($B_к$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_c \times K_{vk},$$

монда:

$B_c$ - мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 5 нче таблицада билгеләнгән күләме;

$K_{vk}$ - сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

24. Мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә, учреждениеләр җитәкчеләре урынбасарларына һәм баш бухгалтерына, акчалар булганда, бер мәртәбә кызыксындыру түләве башкарыла.

Бу максатлар өчен учреждение җитәкчесенә түләүләр Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Бу максатлар өчен учреждение җитәкчесе урынбасарына һәм баш бухгалтерга түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль актлары белән билгеләнә.

25. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

26. Муниципаль мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация характерындагы түләү төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

## 6 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

27. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

2) зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартларында эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

3) нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр.

28. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм тиешле финанс елына муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

29. Аерым учреждениеләрнең урта, әйдәүче звено һәм җитәкчеләр составы вазыйфаларының мәдәният, сәнгать һәм кинематография һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә эшчәнлек үзенчәлеге өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

монда:
$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәнең күләме.
Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр күләме 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләрнең тәкъдим ителә торган күләме

| N т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезе | Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Физик үсешендә кимчелекләр булган затларга хезмәт күрсәтү (күрмәүчеләр, ишетмәүчеләр) | урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| 2. | Милли статуска ия мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә эшләү | әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 30 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 30 |
| 3. | Практик эштә чит тел куллану | әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 5 |

Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфада эшләүнең конкрет шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының исемлеге, сайланулы профсоюз органы (яки мәдәният хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

30. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартларында ($B_{kh}$) эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

монда:

$O_b$ - мәдәният хезмәткәрләренең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләгә өстәмәнең күләме;

$H_{fk}$ - законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$ - Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләре хезмәт хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, дүрт процент күләмендә билгеләнә.

31. Нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификациядә эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

32. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесенең норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акчалар күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

33. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладлар, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәткә түләүгә каралган акчалар хисабына исәпләнә.

34. Татарстан Республикасы муниципаль китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, тиешле чорда (ай, квартал, ел) муниципаль китапханәләрнең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә, кызыксындыру түләүләренә җибәрелә ала.

Хезмәткә түләү фонды экономияләнгән очракта, кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фондындагы экономия барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә түләнә.

Татарстан Республикасы муниципаль китапханәләренең, музейларының, музей тибындагы башка учреждениеләренең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең, эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренең хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрләренә, әлеге чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, тиешле чорда хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артырга тиеш түгел.

Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләвенең күләме Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең, мәдәни-ял учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең, мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчесенә йөкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Муниципаль китапханәләр, музейлар, музей тибындагы башка учреждениеләр һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге

| N т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасы халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның халык артисты |
| 3.2. | СССРның халык рәссамы |

| | |
|---|---|
| 4. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган пропагандист |
| 4.2. | Халык артисты |
| 4.3. | Атказанган артист |
| 4.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5. | Халык рәссамы |
| 4.6. | Атказанган рәссам |
| 4.7. | Халык язучысы |
| 4.8. | Атказанган язучы |
| 4.9. | Халык шагыйре |
| 4.10. | Халык җырчысы |
| 4.11. | Халык акыны |
| 4.12. | Атказанган журналист |
| 4.13. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14. | Атказанган мәдәни-агарту эше хезмәткәре |
| 4.15. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16. | Атказанган китапханәче |
| 4.17. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык артисты |
| 5.3. | Атказанган артист |
| 5.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5. | Халык рәссамы |
| 5.6. | Атказанган рәссам |
| 5.7. | Халык язучысы |

| | |
|---|---|
| 5.8. | Атказанган язучы |
| 5.9. | Халык шагыйре |
| 5.10. | Атказанган журналист |
| 5.11. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12. | Атказанган китапханәче |
| 5.13. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15. | Атказанган фән  эшлеклесе |

Башкарма комитетның
2025 елның 19 февралендәге
1276 номерлы карарына
2 нче кушымта

Муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре (алга таба – мәдәният хезмәткәрләре) вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге нигезләмәдә төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәтенә түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары;

2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

3) компенсация характерындагы түләүләр.

4. Ел саен бирелә торган яки башка ялда булганда, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда башкару сәнгате хезмәткәренең профиль буенча хезмәт стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә бәйле рәвештә хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, хезмәткә түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлардан соң гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләре:

1) белем һәм хезмәт стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының Бердәм квалификация белешмәсе, «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары» бүлеген раслау турында» 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы приказы белән билгеләнгән квалификация характеристикаларына туры килүен тикшерәләр;

2) ел саен муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләре өчен тариф исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

3) муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең хезмәт хакын вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

## 2 бүлек. Башкару сәнгате хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

6. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Аенабаза окладының күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |

| | |
|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Театрларның һәм концерт оешмаларының ярдәмче составы артисты | 24 966 |
| Циркта номер ассистенты | 24 966 |
| Билетлар контролеры | 24 966 |
| «Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 27 658 |
| Цирк дрессировщигы | 27 658 |
| Билет кассалары мөдире | 27 658 |
| Суфлер | 27 658 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Цирк балеты артисты | 27 658 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 27 658 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 27 658 |
| Режиссер ярдәмчесе | 27 658 |
| Сөйләм техникасы буенча репетитор | 27 658 |
| «Әйдәүче звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 27 958 |
| Музыкаль комедия (оперетта), музыкаль-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда хор артисты | 27 958 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Администратор, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән администраторлардан тыш | 27 958 |
| Артист - һава гимнасты | 27 958 |
| «Эвилибр» жанры артисты | 27 958 |

| | |
|---|---|
| Хайваннар дрессурасы жанры артисты | 27 958 |
| Жонглёрлык жанры артисты | 27 958 |
| Иллюзия жанры артисты | 27 958 |
| Ат дрессурасы жанры артисты | 27 958 |
| Келәм артисты, буффонада клоуны, музыкаль эксцентрик, сатирик | 27 958 |
| Җыр һәм бию ансамбле оркестры артисты | 27 958 |
| Спорт - акробатика жанра артисты | 27 958 |
| Опера һәм балет театрларында хор артисты | 27 958 |
| Эстрада оркестры (ансамбль) артисты - өченче - бишенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән артистлардан тыш, оркестрның барлык артистлары | 27 958 |
| Артистлар - концерт башкаручылары (барлык жанрлар), ярдәмче состав артистлары - концерт башкаручыларыннан тыш | 27 958 |
| Тавыш операторы | 27 958 |
| Репертуар буенча редактор | 27 958 |
| Балет буенча репетитор | 27 958 |
| Вокал буенча репетитор | 27 958 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында (оперетта), музыкаль-драма, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда, концерт оешмаларында администратор, өлкән администратор | 27 958 |
| Курчак театры артисты (курчак уйнатучы) | 27 958 |
| Балет артисты | 27 958 |
| Җыр һәм бию ансамбленең, бию коллективының балет артисты | 27 958 |
| Драма артисты | 27 958 |
| Оркестр артисты | 27 958 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) - беренче скрипка һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипка, альт, контрабасларның икенче пультлары, икенче | 27 958 |

| | |
|---|---|
| флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче фагот, икенче һәм дүртенче валторна, икенче торба, икенче тромбон, кечкенә бәрмә инструментлар, икенче арфа, рояль, челеста артисты | |
| Симфония, камера, эстрада-симфония, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты, дүртенче һәм бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 27 958 |
| Җыр һәм бию ансамбле хоры, хор коллективы артисты | 27 958 |
| Артист-вокалчы (солист) | 27 958 |
| Манеж инспекторы (тамаша алып баручы) | 27 958 |
| Вокал (балет) классы концертмейстеры | 27 958 |
| Редактор (музыка редакторы) | 27 958 |
| Цирк номерлары репетиторы | 27 958 |
| Иҗади жанрлар буенча белгеч | 27 958 |
| Яктылык рәссамы | 27 958 |
| Рәссам-бутафор | 27 958 |
| Рәссам-гример | 27 958 |
| Рәссам-декоратор | 27 958 |
| Рәссам-конструктор | 27 958 |
| Театр костюмнары рәссам-модельеры | 27 958 |
| Рәссам-сәхнәгә куючы | 27 958 |
| Рәссам-скульптор | 27 958 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты - концертмейстер һәм беренче скрипка, икенче скрипка, альт, виолончель, контрабас, күрсәтелгән төркем уен коралларының пульты, агач һәм бакыр тынлы уен коралларының беренче тавышлары һәм аларның көйләүчеләре, беренче арфа, бас-тромбон, туба, литавра концертмейстеры һәм концертмейстер урынбасары | 27 958 |
| Симфония, камера, эстрада-симфония, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты - беренче скрипка һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипка, альт, контрабасларның икенче пультлары, икенче флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче һәм дүртенче валторналар, икенче торба, икенче тромбон, кечкенә бәрмә уен кораллары (симфония, камера, эстрада- | 27 958 |

| | |
|---|---|
| симфония оркестрларында), флейта, гобой, фагот концертмейстерлары һәм концертмейстерлар урынбасарлары; беренче, икенче һәм өченче кларнет, валторна, саксофон, торба, тромбон, туба, кларнет, баритон, тенор, бәрмә уен кораллары, контрабаслар (тынлы оркестрларда), концертмейстерлар һәм концертмейстерлар урынбасарлары, рус халык уен коралларында (балалайка, домра, баян, гөслә, жалейка, Владимир рожогы һ. б.) виртуоз уйнаучы оркестр солистлары (халык уен кораллары оркестры өчен) | |
| Лектор-сәнгать белгече (музыка белгече) | 27 958 |
| Баш режиссер (баш дирижер, баш балетмейстер, сәнгать җитәкчесе) ярдәмчесе, труппа мөдире | 27 958 |
| Нәфис сүз остасы | 27 958 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты - әйдәүче концертмейстер, уен кораллары төркеме җитәкчесе | 27 958 |
| Симфония, камера, эстрада-симфония, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты - беренче скрипка һәм виолончельләр, икенче скрипка, альт, контрабасов, бас-тромбон, туба, агач һәм бакыр тынлы уен коралларының беренче тавышлары һәм аларны көйләүчеләр, беренче арфа, литавры, рояль, гитара, аккордеон, кечкенә бәрмә уен кораллары, бәрмә җайланма концертмейстеры һәм концертмейстер ярдәмчесе | 27 958 |
| «Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Тавыш режиссеры | 28 258 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер), икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш ) | 28 258 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Балетмейстер-сәхнәгә куючы, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 28 258 |
| Иҗат коллективы, цирк конвейеры программасы директоры | 28 258 |
| Музыка бүлеге башлыгы, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 28 258 |
| Сәнгать-сәхнәгә кую өлеше мөдире, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 28 258 |

| | |
|---|---|
| Опера һәм балет театрларында режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 28 258 |
| Режиссер-сәхнәгә куючы, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 28 258 |
| Әдәби-драма бүлеге җитәкчесе, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 28 258 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында хореограф | 28 258 |
| Баш балетмейстер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә билгеләнгәннәрдән кала | 28 258 |
| Баш дирижер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә билгеләнгәннәрдән кала | 28 258 |
| Баш директор, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә билгеләнгәннәрдән кала | 28 258 |
| Баш хормейстер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә билгеләнгәннәрдән кала | 28 258 |
| Баш рәссам, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә билгеләнгәннәрдән кала | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, циркларда музыкаль бүлек мөдире | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, концерт залларында, циркларда сәнгать-сәхнәгә кую бүлеге мөдире | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында реңиссер-сәхнәгә куючы | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында әдәби-драма бүлеге мөдире | 28 258 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, циркларда, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында баш балетмейстер | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль | 28 258 |

| | |
|---|---|
| музыка һәм бию коллективларында, симфония, камера, тынлы оркестрларда һәм халык уен кораллары оркестрларында филармонияләр һәм концерт оешмалары составында, циркларда баш дирижер | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, филармонияләрдә һәм концерт оешмаларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, циркларда баш хормейстер | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш режиссер | 28 258 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш рәссам | 28 258 |

## 3 бүлек. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

7. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

монда:

$O_b$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең база оклады;

S - башкару сәнгате хезмәткәре биләгән фактик ставкалар саны.

## 4 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

8. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә башкару сәнгате хезмәткәрен сыйфатлы эш нәтиҗәсенә ирешүгә стимуллаштыруга, шулай ук башкарыла торган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) осталык өчен түләүләр;
2) эш интенсивлыгы өчен түләүләр;
3) мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
4) профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр;
5) башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;
6) премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

9. Осталык өчен түләүләр ($B_м$) әйдәүче звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_m = O_d \times \frac{D_m}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_m$ - осталык өчен өстәмәнең күләме.

Осталык өчен өстәмәләрнең күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Осталык өчен өстәмәләрнең күләме

| Артист категориясе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|
| 2 нче план артисты | 2 |
| 1 нче план артисты | 4 |
| Әйдәүче сәхнә остасы | 6 |

10. Эш интенсивлыгы ($B_{in}$) өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{in} = O_d \times \frac{D_{in}}{100\%},$$

монда:
$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;
$D_{in}$ - эш интенсивлыгы өчен өстәмәнең күләме.
Эш интенсивлыгы өчен өстәмәләрнең күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Эш интенсивлыгы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 1 | 10 |
| | 2 | 17 |
| Әйдәүче звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 1 | 10 |
| | 2 | 25 |
| | 3 | 35 |
| | 4 | 40 |
| | 5 | 43 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 1 | 30 |
| | 2 | 60 |
| | 3 | 70 |
| | 4 | 90 |

11. Башкару сәнгате хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә неңкүләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме сигез процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме 10 процент тәшкил итә.

«Халык артисты» һәм «Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме 20 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме булган башкару сәнгате хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләү, башкару сәнгате хезмәткәренең сайлавы буенча, мактаулы исемнең берсе буенча билгеләнә.

12. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_s$ - профиль буенча хезмәт стажы өстәмә күләме.

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмәнең күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж төркеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәүче звено башкару сәнгате | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәткәрләре вазыйфалары | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

Эш вакыты вазыйфа буенча хезмәт стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Россия Федерациясе хезмәт законнары белән һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан раслана.

Хезмәт стажы үзгәргәндә, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

13. Башкару сәнгате хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре аерым вакыт чоры өчен билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып учреждениенең локаль актлары белән раслана торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет зурлыклары һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәнең чик күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең чик күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 9 |
| Урта звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 15 |
| Әйдәүче звено башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 18 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкчеләр составы вазыйфалары | 25 |

14. Башкару сәнгате хезмәткәрләренә юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә һәм билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнә.

15. Башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча башкару сәнгате хезмәткәрләренә акчалар булганда бер тапкыр кызыксындыру түләве башкарыла. Бу максатлар өчен түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

16. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локальнорматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

## 5 бүлек. Учреждение җитәкчесенең, җитәкче урынбасарының һәм баш бухгалтерының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

17. Учреждениеләр җитәкчеләренең (шул исәптән сәнгать), җитәкчеләр урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы вазыйфаи окладтан һәм стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрдән тора.

18. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенең окладыхезмәткә түләү буенча төркемгә бәйле рәвештә билгеләнә. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесе хезмәтенә түләү төркеме башкару сәнгате учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына бәйле рәвештә билгеләнә.

19. Учреждениеләрнең җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының окладлары әлеге учреждениеләр җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк итеп билгеләнә.

20. Җитәкчеләрнең хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләме 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең база оклады

| Учреждение төре | Аена оклад күләме, мең сум |
|---|---|
| | Хезмәткә түләү төркеме |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар |

| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500.999 га кадәр | 501 дән артык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Театр | - | - | 50,0 | 52,0 | 55,0 | 65,0 | 65,0 | 70,0 |
| Концерт оешмалары | - | 50,0 | 55,0 | 60,0 | 65,0 | 70,0 | - | - |

21. Башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм аларның авырлык коэффициентлары Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне башкарган өчен түләнергә мөмкин.

Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләме 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

Башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме

| Учреждение төре | Аена башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәткә түләү төркеме | | | | | | | |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999га кадәр | 51 дән 75,999га кадәр | 76 дан 150,999га кадәр | 151 дән 300,999га кадәр | 301 дән 500.999га кадәр | 501 дән артык |
| Театр | - | - | 6,0 | 6,5 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | 7,5 |
| Концерт оешмалары | - | 6,0 | 6,5 | 7,0 | 7,0 | 7,5 | - | - |

22. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен мәдәният учреждениесе җитәкчесе урынбасарына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәдәният учреждениесе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин. Җитәкче урынбасарына, баш бухгалтерга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең чик дәрәҗәсе мәдәният учреждениесе җитәкчесенең башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

23. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ($В_к$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$В_k = В_c \times K_{vk},$$

монда:

$В_c$ – башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 6 нчы таблицада билгеләнгән күләме;

$K_{vk}$ - сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

24. Башкару сәнгате учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча учреждениеләр җитәкчеләренә (шул исәптән сәнгать), учреждениеләр җитәкчеләре урынбасарларына һәм баш бухгалтерына, акчалар булганда, бер мәртәбә кызыксындыру түләве башкарыла.

Бу максатлар өчен учреждение җитәкчесенә, шул исәптән сәнгать җитәкчесенә түләүләр Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Бу максатлар өчен учреждение җитәкчесе урынбасарына һәм баш бухгалтерга түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль актлары белән билгеләнә.

25. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

26. Башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация характерындагы түләү төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

## 6 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

27. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартларында эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә түләүләр;

2) нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр.

28. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм тиешле финанс елына башкару сәнгате учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

29. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартлары булган эшләрдә ($В_{kh}$) эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

монда:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәнең күләме;

$H_{fk}$ - законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактик эшләнгән вакыт;

$H_n$ - Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, дүрт процент күләмендә билгеләнә.

30. Нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификациядә эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## 7 бүлек. Хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм файдалану тәртибе

31. Башкару сәнгате учреждениеләренең хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесенең норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән акчалар күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм башкару сәнгате учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

32. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладлар, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр башкару сәнгате учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә башкару сәнгате учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында агымдагы финанс елына хезмәткә түләүгә каралган акчалар хисабына исәпләнә.

33. Башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү, тиешле чорда (ай, квартал, ел) башкару сәнгате учреждениеләренең әлеге нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә, кызыксындыру түләүләренә җибәрелә ала.

Хезмәткә түләү фонды экономияләнгән очракта, кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фондындагы экономия барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә түләнә.

Муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең, эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренең хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәрләренә, әлеге чорда эшләнгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, тиешле чорда хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына башкарылган кызыксындыру түләвенең күләме агымдагы елның 1 гыйнварына «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артырга тиеш түгел.

Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләвенең күләме Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

Башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларнең мактаулы исемнәре исемлеге

| N т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасы халык язучысы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.3. | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган пропагандист |
| 4.2. | Халык рәссамы |
| 4.3. | Атказанган рәссам |
| 4.4. | Халык язучысы |

| | |
|---|---|
| 4.5. | Атказанган язучы |
| 4.6. | Халык шагыйре |
| 4.7. | Халык җырчысы |
| 4.8. | Халык акыны |
| 4.9. | Атказанган журналист |
| 4.10. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11. | Атказанган мәдәни-агарту эше хезмәткәре |
| 4.12. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.13. | Атказанган китапханәче |
| 4.14. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.15. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.16. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык рәссамы |
| 5.3. | Атказанган рәссам |
| 5.4. | Халык язучысы |
| 5.5. | Атказанган язучы |
| 5.6. | Халык шагыйре |
| 5.7. | Атказанган журналист |
| 5.8. | Атказанган китапханәче |
| 5.9. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.10. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.11. | Атказанган фән эшлеклесе |

Башкарма комитетның
2025 елның 19 февралендәге
1276 номерлы карарына
3 нче кушымта

Муниципаль мәдәният учреждениеләренең
фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре
вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең
хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге нигезләмәдә төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) оклад (вазыйфаи оклад), хезмәт хакы ставкалары;
2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;
3) компенсация характерындагы түләүләр.

4. Ел саен бирелә торган яки башка ялда булганда, вакытлыча хезмәткә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең профиль буенча хезмәт стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, фәннәр докторы яки фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе бирелүгә бәйле рәвештә хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокукы барлыкка килгәндә, хезмәткә түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлардан соң гамәлгә ашырыла.

2 бүлек. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

5. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Фәнни хезмәткәрләр | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Кече фәнни хезмәткәр | 29 158 |
| Фәнни хезмәткәр | 29 158 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |

| | |
|---|---|
| Өлкән фәнни хезмәткәр | 29 958 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Әйдәүче фәнни хезмәткәр | 30 458 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Баш фәнни хезмәткәр | 30 958 |
| Структур бүлекләр җитәкчеләре | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Гыйльми секретарь | 30 958 |

«Музейның кече фәнни хезмәткәре» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрнең база окладының күләме 29 158 сум күләмендә билгеләнә.

«Музейның фәнни хезмәткәре» һәм «музейның өлкән фәнни хезмәткәре» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрнең база окладының күләме 29 958 сум күләмендә билгеләнә.

## 3 бүлек. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладын формалаштыру тәртибе

6. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладый ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

монда:

$O_b$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база окладый күләме;

$S$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре биләгән фактик ставкалар саны.

## 4 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

7. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы эш нәтиҗәсенә ирешүгә стимуллаштыруга юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләү керә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;

2) гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр;

3) профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр;

4) башкарыла торган эшнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

5) премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре;

8. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$O_r$ – фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладый;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме сигез процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмәнең күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәренең исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада бирелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләрнең күләме мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан күбрәк мактаулы исеме булган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә түләү, фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең сайлавы буенча, мактаулы исемнең берсе буенча билгеләнә.

9. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{usz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{usz} = O_d \times \frac{D_{usz}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{usz}$ - гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Бердәм гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр реестрына кертелгән гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр өчен бирелә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр күләмен билгеләү гыйльми дәрәҗә бирү турында карар үз көченә кергән көннән башкарыла. Фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе президиумы тарафыннан кабул ителгән көннән үз көченә керә. Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе президиумы тарафыннан фәннәр кандидаты дипломын бирү турында карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Гыйльми исемнәр булган өчен түләүләр күләмен билгеләү гыйльми исем бирелгән көннән башкарыла.

Фәнни тикшеренүләр өлкәсенең гыйльми дәрәҗәсе һәм гыйльми исеме булган хезмәткәрләренә гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр күләме гыйльми дәрәҗә һәм гыйльми исем өчен түләүләр суммасында исәпләнә.

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмәләрнең күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмәләрнең күләме

| Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмәләр билгеләү нигезе | Өстәмәләрнең күләме, процент | |
|---|---|---|
| | муниципаль учреждениеләрдә | региональ әһәмияткә ия учреждениеләрдә |
| 1 | 2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе | 20 | 60 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | 10 | 30 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча профессор гыйльми исеме | 40 | 80 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасы нигезендә фән тармагы буенча доцент гыйльми исеме | 20 | 40 |

10. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмәнең күләме.

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

Пофиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмәләрнең күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 1 - 4 | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | | 25 елдан артык | 22 |

Хезмәт стажы үзгәргәндә, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән яки стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

11. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып учреждениенең локаль актлары белән раслана торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет зурлыклары һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары, учреждение алдында торган бурычлардан чыгып, ел саен билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_k$ – башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәнең чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең чик күләмнәре 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмәләрнең чик күләмнәре

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмәнең күләме, процент |
|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 1 | 22 |
| | 2 | 22 |
| | 3 | 22 |
| | 4 | 40 |

12. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә һәм билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә түләнә.

13. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә акчалар булганда бер тапкыр кызыксындыру түләве башкарыла. Бу

максатлар өчен түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

14. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локальнорматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

## 5 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

15. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартларында эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә түләүләр;

2) нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр.

16. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә коллектив шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән һәм тиешле финанс елына муниципаль мәдәният учреждениеләренең хезмәткә түләүнең расланган фонды чикләрендә билгеләнә.

17. Зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус эш шартларында эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_d \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

монда:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәнең күләме;

$H_{fk}$ - законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактик эшләнгән вакыт, сәгатьләрдә;

$H_n$ - Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы (база окладь) өчен сәгатьләр нормасы.

Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, дүрт процент күләмендә билгеләнә.

18. Нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификациядә эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Муниципаль мәдәният учреждениеләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә кушымта

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге

| N т/б | Мактаулы исемнең, дәүләт бүләгенең исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.2. | Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе |
| 2.3. | Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.2. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.3. | Атказанган югары мәктәп эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 4.2. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.5. | Атказанган фән эшлеклесе |

Башкарма комитетның
2025 елның 19 февралендәге
1276 номерлы карарына
4 нче кушымта

Муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният,
сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре
хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең (алга таба - мәдәният эшчеләре) хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге нигезләмәдә төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Мәдәният эшчеләренең хезмәт хакы (хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

1) окладлар (вазыйфаи окладлар), хезмәт хакы ставкалары;
2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;
3) компенсация характерындагы түләүләр.

2 бүлек. Мәдәният эшчеләренең база окладларын билгеләү

6. Мәдәният эшчеләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база оклады, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 398 |
| «Икенче дәрәҗә гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21 539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21 713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21 891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22 422 |

Мәдәният эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренең
квалификация дәрәҗәсе буенча эшче һөнәрләре

| N т/б | Мәдәният эшчеләре һөнәрләре |
|---|---|

| 1 | 2 |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| 1.1. | Клавишлы уен кораллары детальләрен әзерләү буенча автоматчы |
| 1.2. | Телле уен кораллары арматурчысы |
| 1.3. | Чиртмә уен кораллары аэрографисты |
| 1.4. | Бутафор |
| 1.5. | Музыка уен кораллары гарнировщигы |
| 1.6. | Мехлы камералар гофрлаучы |
| 1.7. | Гример-постижер |
| 1.8. | Уен автоматлары, аттракционнар һәм тир залы дежуры |
| 1.9. | Тавыш планкаларын тутыручы |
| 1.10. | Тавыш планкалары ясаучы |
| 1.11. | Тынлы уен кораллары өчен детальләр ясаучы |
| 1.12. | Субтитрлар җитештерүче |
| 1.13. | Киномеханик |
| 1.14. | Клавиатурачы |
| 1.15. | Колорист |
| 1.16. | Музыка уен кораллары  детальләрен комплектлаучы |
| 1.17. | Контуровщик |
| 1.18. | Костюмер |
| 1.19. | Декорацияләр бизәлеше буенча маляр |
| 1.20. | Сәхнә  машинисты |
| 1.21. | Негатив монтажчысы |
| 1.22. | Позитив монтажчысы |
| 1.23. | Сәхнә монтировщигы |
| 1.24. | Перламутр  эшкәртүче |
| 1.25. | Магнит язма операторы |
| 1.26. | Клавишлы уен коралларын уйнату стенды операторы |
| 1.27. | Яктыручы |

| | |
|---|---|
| 1.28. | Диапозитив фильмнар операторы |
| 1.29. | Субтитрлар бастыручы |
| 1.30. | Пиротехник |
| 1.31. | Мультипликацион рәсемнәргә нигез әзерләүче |
| 1.32. | Музыкаль уен коралларын полировкалаучы |
| 1.33. | Постижер |
| 1.34. | Фильерлар шомартучы |
| 1.35. | Реквизитор |
| 1.36. | Субтитр ретушеры |
| 1.37. | Тынлы уен кораллары җыючы |
| 1.38. | Бәрмә уен кораллары җыючы |
| 1.39. | Телле уен кораллары җыючы |
| 1.40. | Клавишлы уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.41. | Смычоклы уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.42. | Чиртмә уен коралларын җыючы-монтажлаучы |
| 1.43. | Махсус агач эшкәртү станогы станокчысы |
| 1.44. | Махсус металл эшкәртү станогы станокчысы |
| 1.45. | Декорацияләр эшләү буенча балта остасы |
| 1.46. | Музыка уен кораллары детальләрен һәм узелларын ясау һәм ремонтлау буенча балта остасы |
| 1.47. | Кыл чорнаучы |
| 1.48. | Кылчы |
| 1.49. | Мультипликаця пробалары төшерүче |
| 1.50. | Диапозитив фильмнар җыючы |
| 1.51. | Униформист |
| 1.52. | Декорацияләр куючы |
| 1.53. | Ладовая пластина урнаштыручы |
| 1.54. | Фильм тикшерүче |
| 1.55. | Фильмотекарь |
| 1.56. | Фототекарь |

| «Икенче дәрәҗә мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.1.1. | Клавишлы уен кораллары рамнарын бронзалаучы |
| 2.1.2. | Видеотекарь |
| 2.1.3. | Уен курчаклары ясаучы |
| 2.1.4. | Клавишлы уен кораллары өчен чүкечләр ясаучы |
| 2.1.5. | Музыка уен кораллары контролеры |
| 2.1.6. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.1.7. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.8. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.9. | Кинотелевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.10. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.11. | Телевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.12. | Кинотехнологик җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.1.13. | Пианино һәм рояльләр көйләүче |
| 2.1.14. | Чиртмә уен коралларын көйләүче |
| 2.1.15. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.1.16. | Видеоязма операторы |
| 2.1.17. | Киноустановканың идарә пульты операторы |
| 2.1.18. | Пианино һәм рояльләр регулировщигы |
| 2.1.19. | Телле уен кораллары регулировщигы |
| 2.1.20. | Клавишлы уен кораллары реставраторы |
| 2.1.21. | Бәрмә инструментлар реставраторы |
| 2.1.22. | Фильм күчермәләре реставраторы |
| 2.1.23. | Чиртмә һәм смычоклы уен кораллары реставраторы |
| 2.1.24. | Телле уен кораллары реставраторы |
| 2.1.25. | Фонотекарь |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.2.1. | Уен курчаклары ясаучы |

| | |
|---|---|
| 2.2.2. | Индивидуаль заказ буенча музыка уен кораллары ясаучы |
| 2.2.3. | Интонировщик |
| 2.2.4. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.2.5. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.6. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.7. | Кинотелевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.8. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.9. | Телевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.10. | Кинотехнологик җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.2.11. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.2.12. | Смычоклы уен коралларын көйләүче-регулировщик |
| 2.2.13. | Видеоязма операторы |
| 2.2.14. | Тынлы уен кораллары реставраторы |
| 2.2.15. | Фильм күчермәләре реставраторы |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| 2.3.1. | Кинотелевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.2. | Телевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.3. | Кинотехнологик җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.3.4. | Видеоязма операторы |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Беренче - өченче квалификация дәрәҗәсенә караган, мөһим (аеруча мөһим) һәм җаваплы (аеруча җаваплы) эшне башкаручы эшче һөнәрләре | |
| 2.4.1. | Уен курчаклары ясаучы |
| 2.4.2. | Индивидуаль заказ буенча музыка уен кораллары ясаучы |
| 2.4.3. | Интонировщик |
| 2.4.4. | Музыка уен кораллары контролеры |
| 2.4.5. | Постижер производствосында буяучы |
| 2.4.6. | Җил җайланмаларына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.7. | Тавыш техникасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.8. | Кинотелевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |

| | |
|---|---|
| 2.4.9. | Төшерү аппаратурасына хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.10. | Телевизион җиһазларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.11. | Кинотехнологик җиһазларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү механигы |
| 2.4.12. | Тынлы уен коралларын көйләүче |
| 2.4.13. | Пианино һәм рояльләр көйләүче |
| 2.4.14. | Чиртмә уен коралларын көйләүче |
| 2.4.15. | Телле уен коралларын көйләүче |
| 2.4.16. | Смычоклы уен коралларын көйләүче-регулировщик |
| 2.4.17. | Видеоязма операторы |
| 2.4.18. | Пианино һәм рояльләр регулировщигы |
| 2.4.19. | Тынлы уен кораллары рестараторы |
| 2.4.20. | Клавишлы уен кораллары реставраторы |
| 2.4.21. | Бәрмә уен кораллары реставраторы |
| 2.4.22. | Фильм күчермәләре реставраторы |
| 2.4.23. | Чиртмә һәм смычоклы уен кораллары реставраторы |
| 2.4.24. | Телле уен кораллары реставраторы |

5. Берьюлы ике урында, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче мәдәният эшчеләренең хезмәтенә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яисә башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук берьюлы ике урында эшләү тәртибендә биләгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмен билгеләү һәр вазыйфа өчен аерым башкарыла.

## 3 бүлек. Мәдәният эшчеләренең вазыйфаи окладын формалаштыру тәртибе

6. Мәдәният эшчеләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times \frac{H_f}{H_n},$$

монда:

$O_b$ - мәдәният эшчеләренең база оклады күләме;

$H_f$ - хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы чикләрендә мәдәният эшчеләренең эш сәгатьләренең фактик саны;

$H_n$ - мәдәният эшчеләре хезмәт хакының база ставкасы (база оклады ) өчен сәгатьләр нормасы (хезмәткәр өчен билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы).

## 4 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

7. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы эш нәтиҗәсәсенә ирешүгә стимуллаштыруга юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләү керә.

8. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;

2) премия һәм башка кызыксындыру түләүләре.

9. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($В_{pz}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$В_{pz} = О_{d} \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда:

$О_{d}$ - мәдәният эшчеләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме.

Мактаулы исемнәр булган өчен өстәмәнең күләме 3 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре әлеге Нигезләмә гәкушымтада бирелгән.

Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике яки аннан күбрәк мактаулы исемнәре булган мәдәният эшчеләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча, мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

10. Мәдәният эшчеләренә юбилей даталары, аерымлык билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, бүләкләр алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча премия һәм башка кызыксындыру түләүләре аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, тәртибе һәм шартлары мәдәният учреждениеләренең локаль норматив актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

Мәдәният эшчеләренә премия түләүләренә каралган хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме окладлар (хезмәт хакы ставкалары, вазыйфаи окладлар) һәм хезмәткәрләргә төп вазыйфасы һәм төп эш урыны буенча стимуллаштыру характерындагы түләүләр түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә ике процентын тәшкил итә.

Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча мәдәният эшчеләренә акчалар булганда бер тапкыр кызыксындыру түләве башкарыла. Бу максатлар өчен түләү тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

16. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары учреждениенең локальнорматив хокукый актлары һәм коллектив шартнамәләре белән билгеләнә.

## 5 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

11. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч эш шартларында эшләүче мәдәният эшчеләренә түләүләр;

2) нормаль шартлардан тайпылган шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш башкарылган эш өчен, төнлә һәм нормаль шартлардан тайпылган башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр.

